# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "БОЛГАР ШӘҺӘРЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 43-1 «21 » ноябрь 2024 ел

«Туристлык салымы турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 33.1 бүлеге нигезендә, “Болгар шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставына, “Болгар шәһәре” муниципаль берәмлеге советына таянып, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының “Болгар шәһәре” муниципаль берәмлеге Советы карар кылды:

1. 2025 елның 01 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә туристлык салымы билгеләргә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә: 2025 елда – 1 процент, 2026 елда – 2 процент, 2027 елда – 3 процент, 2028 елда - 4 процент, 2029 елдан башлап-5 процент.

3. Салым түләү тәртибен Россия Федерациясе Салым кодексының 418.8 статьясы нигезендә билгеләргә.

4. Вакытлыча яшәү буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясе салым базасына кертелми торган физик затлар категорияләре Россия Федерациясе Салым кодексының 418.4 статьясының 2 пункты белән билгеләнгән.

5. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә туристлык салымын исәпләү тәртибе Россия Федерациясе Салым кодексының 418.7 статьясы нигезендә билгеләнә.

Россия Федерациясе Салым кодексының 418.7 статьясы нигезендә исәпләнгән туристлык салымы суммасы 100 сум һәм яшәү тәүлеге санының тапкырлавы буларак исәпләнгән минималь туристлык салымы суммасыннан кимрәк булган очракта, туристлык салымы суммасы минималь туристлык салымы күләмендә билгеләнә.

6. Әлеге карарның 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керүен билгеләргә.

7. Әлеге карарны «Яңа тормыш» район газетасында (Новая жизнь), Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru, һәм хокук мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР Спас муниципаль районының Болгар шәһәр Башкарма комитетына йөкләргә.

«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге
Башлыгы урынбасары К.А.Молодов